**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлегенең Рангазар авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2002 елның 13 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең Рантамак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рантамак авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Рангазар авылларында урамнарны яктырту, яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру;
- Беларус-320.4 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
- Рангазар авылларында кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
-Рангазар авыл зиаратында биек агачларны кисүгә( килешү буенча эшләү өчен түләү)
-Рангазар авылында биек агачларны кисүгә (килешү буенча эшләү өчен түләү)
-Рангазар авылының киров урамына шлагбаум үзерләү һәм урнаштыру өчен.
3. Әлеге карарны Рангазар авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Р. Шарипова